ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» мая 2026 ел № 127

«Әгерҗе муниципаль районында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 июнендәге 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРТ:

1. «Әгерҗе муниципаль районында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 июнендәге 188 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарларны преамбуладан төшереп калдырырга: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карары;

1.2. Карар (алга таба - Административ регламент) белән расланган Әгерҗе муниципаль районында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт торак фонды - «Татарстан Республикасы Раиса каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы;

1.3. Административ регламентның 2.6.1 пунктындагы 12,17,18

пунктчаларында, «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзтезмәсен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды»на алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**